СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

____________№____________

На № 42/7 от 27.08.2021

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертүне раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 30-32 статьялары, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге генераль планына үзгәрешләр кертү проектына 2020 елның 22 июнендәге 10-53/7789 номерлы Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошин кул куйган бәяләмә нигезендә, 2020 елның 26 маенда уздырылган халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча һәм Бәтке авыл җирлеге Советының 2020 елның 29 июнендәге 8/1 номерлы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге генераль планына үзгәрешләр кертү» проектын килештерү турында» карарын исәпкә алып, район уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертүне расларга.
2. Бәтке авыл җирлеге Советының 2012 елның 7 ноябрендәге 43 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең генераль планын барлык үзгәрешләре белән юкка чыгарырга.
3. Бәтке авыл җирлеге Советының 2012 елның 7 ноябрендәге 43 карары үз көчен югалткан дип санарга.
4. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы урынбасары

Р.И. Закиров